ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

"Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында" Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында"

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 31маенда
кабул ителде

1 статья

"Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында" 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 5; 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 8 – 9), "2017 елның 1 гыйнварыннан" сүзләрен "2018 елның 1 гыйнварыннан" сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон 2017 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 31 мае
№ 39-ТРЗ